КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.08.2024 № 428-П

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының торышына, аларны тотуга, саклап калуга, алардан файдалануга, аларны популярлаштыруга, тарихи җирлекләрнең сак предметына һәм дәүләт саклавына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда (контрольдә тотылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яисә үтәлмәве турында таныклык бирә торган контроль сораулар исемлеге) кулланыла торган тикшерү кәгазе формасын раслау турында

2020 нче елның 31 нче июлендә гамәлгә кергән «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ номерлы Федераль закон, 2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында»гы 73-ФЗ номерлы Федераль закон, 2005 нче елның 1 нче апрелендә гамәлгә кергән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»гы 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 нче елның 27 октябрендәге «Тикшерү кәгазьләре формалары проектларын әзерләүгә, эчтәлегенә, иҗтимагый фикер алышуга, тикшерү кәгазьләре формаларын раслауга, куллануга, актуальләштерүгә, шулай ук тикшерү кәгазьләрен мәҗбүри куллану очракларына карата таләпләрне раслау турында»гы 1844 номерлы карары нигезендә боерам:

1. Әлеге боерыкка караган кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, ачыкланган объектларның торышына, аларны тотуга, саклап калуга, алардан файдалануга,

аларны популярлаштыруга, мәдәни мирас, тарихи җирлекләрнең сак предметын һәм дәүләт саклавына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазенең (җаваплары тикшереп торылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яисә үтәлмәве турында таныклык бирә торган контроль сораулар исемлегенең) кушымтада бирелә торган формасын расларга.

2. Дәүләт күзәтчелеге (контроль) һәм суд-административ практика бүлегенә мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитетының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында әлеге боерыкны урнаштыру эшен оештырырга.

3. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2024 нче елның 26 нчы августындагы 428-П номерлы боерыгы белән расланды

Форма

| |
|---|
| Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 нче елның 16 нчы апрелендәге 604 нче номерлы карары белән расланган контроль (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләренең 21 нче пунктында каралган QR-код |

**Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының, Тарихи җирлекләрнең саклау предметының торышына, тотуына, саклап калуына, алардан файдалануына, аларны популярлаштыруына һәм дәүләт саклавына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган (җаваплары тикшереп торылучы зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яисә үтәлмәве турында таныклык бирә торган контроль сораулар исемлеге)**

**ТИКШЕРҮ КӘГАЗЕ**

1. Контроль (күзәтчелек)төрләренең бердәй реестрына кертелгән региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) төренең исеме:______________________________________________

2. Контроль (күзәтчелек) органының исеме:_________________________________

3. Тикшерү кәгазе формасын раслау турында норматив хокукый акт реквизитлары: ______________________________________________________________________

4. Контроль (күзәтчелек) чарасының төре: ____________________________________

5. Тикшерү кәгазен тутыру датасы: ____________________________________________

6. Контроль (күзәтчелек) чарасы уздырыла торган региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты:______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

7. Тикшереп торылучы зат турында белешмәләр: гражданның яисә индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), аның салым түләүчесе буларак

идентификация номеры һәм (яисә) индивидуаль эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, гражданны яисә индивидуаль эшкуарны теркәү адресы, юридик затның исеме, салым түләүчесе буларак идентификация номеры һәм (яисә) төп дәүләт теркәү номеры, контрольдә тотылучы затлар булып торучы юридик затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) теркәү номеры, адресы: ______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________

8. Тикшерү кәгазен тутырып, контроль (күзәтчелек) чарасын уздыру урыны (урыннары):______________________________________________
______________________________________________

9. Вәкаләтле вазыйфаи зат имзалаган контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турындагы Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау Комитеты акты реквизитлары: ______________________________________________

10. Контроль (күзәтчелек) чарасының исәп номеры: ____________________________

11. Вазыйфаи бурычларына региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) формасы турындагы нигезләмә, вазыйфаи регламент яисә вазыйфаи инструкция нигезендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) төре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүче һәм тикшерү кәгазен тутыручы контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү (алга таба - инспектор) вәкаләтләрен гамәлгә ашыру керә торган контроль (күзәтчелек) органы вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары:
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________

12. Җаваплары контрольдә тотылучы затның мәҗбүри таләпләрне үтәвен яисә үтәмәвен раслый торган, мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган контроль сораулар исемлеге:

| № | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыра торган сораулар | Структур берәмлекләре күрсәтелгән, норматив хокукый актларның реквизитлары | Сорауларга җаваплар | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **әйе** | **юк** | **кулланугa рөхсәт ителми** | |
| 1. | Мәдәни мирас объектының физик сакланышын һәм сак предметын саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән фәнни-тикшеренү, эзләнү, проект эшләрен, консервацияләүне, ремонтлауны, реставрацияләүне финанслау һәм оештыру тәэмин ителәме? | 2002 нче елның 25 нче июнендәге «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында»гы 73-ФЗ номерлы Федераль законның 472 нче статьясындагы 3 нче | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | пунктның 1 нче пунктчасы (алга таба – 73-ФЗ номерлы Федераль закон) | | | | |
| 2. | Мәдәни мирас объектын карап торуга һәм аны тиешле техник, санитар һәм янгынга каршы куркынычсыз халәттә тотуга чыгымнар бармы? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^3$ нче статьясындагы 1 нче пунктның 1 нче пунктчасы | | | | |
| 3. | Мәдәни мирас объектының сак предметын үзгәртә торган яисә мәдәни мирас объектын саклау өчен кирәкле шартларны начарайта торган эшләр башкарылганмы? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^3$ нче статьясындагы 1 нче пунктның 2 нче пунктчасы | | | | |
| 4. | Ачыкланган мәдәни мирас объектының, мәдәни мирас объектының тышкы кыяфәтен, күләм-планлаштыру һәм конструктив чишелешләрен һәм структураларын, интерьерын үзгәртә торган эшләр башкарылдымы?<br><br>Искәрмә: сорау мәдәни мирас объектының сак предметы билгеләнмәгән очракта бирелә. | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^3$ статьясындагы 1 нче пунктның 3 нчепунктчасы | | | | |
| 5. | Реестрга кертелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә эшчәнлекне гамәлгә ашыруга карата 73-ФЗ номерлы Федераль законның $5^1$ статьясында билгеләнгән таләпләр үтәләме, мәдәни мирас объекты урнашкан җир кишәрлегеннән, су объектыннан яисә аның өлешеннән файдалануның махсус режимы үтәләме? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^3$ статьясындагы 1 нче пунктның 5 нчепунктчасы | | | | |
| 6. | Мәдәни мирас объекты (янгынга каршы куркынычсызлык таләпләрен исәпкә алып җиһазландырылган, түбәндә күрсәтелгән хуҗалык эшчәнлеге төрләрен гамәлгә ашыру һәм (яисә) тәэмин итү өчен билгеләнгән йә мәдәни мирас | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^3$ статьясындагы 1 нче пунктның 6 нчы пунктчасы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | объектларыннан һәм дини билгеләнештәге әйберләрне, шәмнәрне һәм лампа маен да кертеп, саклау урыннарыннан тыш) файдаланыламы?:<br><br>мәдәни мирас объекты интерьерын, аның фасадын, территориясен һәм су объектларын пычратучы һәм (яисә) зарарлы пар-газ һәм башка бүлеп чыгарулары булган шартлагыч һәм яну куркынычы булган материаллар, предметлар һәм матдәләр складлары һәм җитештерү объектлары өчен;<br><br>әлеге җиһазның куәтенә карамастан, Мәдәни мирас объекты конструкциясенә динамик һәм вибрацион йогынты ясый торган җиһазлары булган җитештерү объектлары өчен;<br><br>мәдәни мирас объекты өчен уңайсыз температура-дымлылык режимы һәм химик актив матдәләр куллану белән бәйле җитештерү объектлары һәм лабораторияләр өчен? | | | | | |
| 7. | Дәүләт күзәтчелеге органына тикшерелүче затка билгеле булган мәдәни мирас объектына, мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендәге җир кишәрлегенә зыян китергән яки мондый зыян китерү куркынычы тудырган барлык зыян, аварияләр турында кичекмәстән хәбәр ителгәнме һәм алга таба җимерелүне булдырмау буенча кичекмәстән чаралар күрелгәнме, шул исәптән аварияләргә каршы эшләр мәдәни мирас объектын саклау эшләрен башкару өчен билгеләнгән тәртиптә башкарылганмы? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^3$ статьясындагы 1 нче пунктның 7 нче пунктчасы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 8. | Мәдәни мирас объекты территориясенең хәле начараюга юл куелмаганмы, мәдәни мирас объекты территориясе төзек хәлдә кулланыламы? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^3$ статьясындагы 1 нче пунктның 8 нче пунктчасы | | | | |
| 9. | Саклануны тәэмин итүгә карата таләпләр (Мәдәни мирас объектының тышкы кыяфәтенең үзгәрешсезлеген тәэмин итүгә, бөтенлеген, структурасын саклап калуга карата таләпләр) яисә әлеге мәдәни мирас объектында коткару эшләрен оештыру һәм финанслау буенча таләпләр үтәләме? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^2$ статьясындагы 3 нче пункт | | | | |
| 10. | Мәдәни мирас объектларында мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштырылганмы? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның 27 нче статьясының 1-3 нче пунктлары | | | | |
| 11. | Мәдәни мирас объектларында, шулай ук аларның территорияләрендә тышкы реклама урнаштырылганмы?<br><br>Искәрмә: мәдәни мирас объектларында, шулай ук аларның территорияләрендә тышкы рекламаны таратмау турындагы таләп мәдәни мирас объектларында, аларның территорияләрендә бары тик мәдәни мирас объектларында, аларның территорияләрендә театраль-тамаша, мәдәни-агарту һәм тамаша-күңел ачу чаралары уздыру турындагы мәгълүмат, яисә бары тик күрсәтелгән билгеле бер затны конкрет чараның иганәчесе буларак искә алу шарты белән, әгәр дә мондый искә алуга реклама мәйданының (пространствоның) ун проценттан артыгы бирелмәгән булса. | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $35^1$ нче статьясының 1-3 нче пунктлары | | | | |
| 12. | Саклау зонасы, шул исәптән бердәм саклау зонасы чикләрендә җирләрдән файдалану режимына һәм шәһәр төзелеше | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 нче елның 12 нче сентябрендәге 972 нче номерлы карары | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | регламентларына карата таләпләр үтәләме:<br>а) мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше һәм (яисә) табигать мохитен саклап калуга һәм торгызуга (регенерацияләүгә) юнәлдерелгән махсус чаралар кулланудан тыш, капиталь төзелеш объектлары төзүне тыю (тарихи-шәһәр төзелеше һәм(яисә) табигать мохитенең өлешчә яисә тулысынча юкка чыккан элементларын һәм(яисә) характеристикаларын торгызу, тулыландыру);<br>б) капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен капиталь ремонтлауны һәм реконструкцияләүне чикләү, шул исәптән аларның зурлыкларына, пропорцияләренә һәм параметрларына, аерым төзелеш материалларыннан файдалануга, төсләр чишелешләрен куллануга, детальләрнең үзенчәлекләренә һәм кече архитектура формаларына кагылышлы;<br>в) мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү өчен кирәкле хуҗалык эшчәнлеген чикләү, шул исәптән реклама, вывескалар, вакытлыча корылмалар һәм объектлар (автостоянкалар, киосклар, түбәләр)урнаштыруны тыю яисә чикләү;<br>г) Тарихи-шәһәр төзелеше һәм табигать мохитенең шәһәр төзелеше (планлаштыру, типологик, масштаблы) характеристикаларын, шул исәптән шәһәр барлыкка китерүче барлык тарихи кыйммәткә ия объектларны саклап калу;<br>д) мәдәни мирас объектын визуаль кабул итүне тәэмин итү. | белән расланган Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау зоналары турында нигезләмәнең 34 нче статьясы, 9 нчы пункты | | | | |
| 13. | Төзелешне һәм хуҗалык | 73-ФЗ номерлы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | эшчәнлеген җайга салу зонасы, шул исәптән төзелешне һәм хуҗалык эшчәнлеген җайга салуның бердәм зонасы чикләрендә җирләрдән файдалану режимына һәм шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр үтәләме:<br>а) мәдәни мирас объектының тарихи мохитендә сакланышын тәэмин итү өчен кирәкле төзелешне чикләү, шул исәптән капиталь төзелеш объектларының һәм аларның өлешләренең зурлыкларына, пропорцияләренә һәм параметрларына, аерым төзелеш материалларыннан файдалануга, төсләр чишелешләрен куллануга кагылышлы;<br>б) капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен капиталь ремонтлауны һәм реконструкцияләүне чикләү, шул исәптән аларның зурлыкларына, пропорцияләренә һәм параметрларына, аерым төзелеш материалларыннан файдалануга, төсләр чишелешләрен куллануга кагылышлы;<br>в) мәдәни мирас объектын аның тарихи-шәһәр төзелеше һәм табигать мохитендә визуаль кабул итүне тәэмин итү;<br>г) мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше һәм табигать мохитендә сакланышын тәэмин итү өчен кирәкле хуҗалык эшчәнлеген чикләү;<br>д) мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше һәм табигать мохитендә сакланышын тәэмин итү өчен кирәкле әйләнә-тирә мохит сыйфатын саклау;<br>е) мәдәни мирас объектының тарихи һәм ландшафт | Федераль законның 34 нче статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 нче елның 12 нче сентябрендәге 972 нче номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау зоналары турындагы Нигезләмәнең 10 нчы пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | даирәсендә, шулай ук саклана торган табигый ландшафтта саклануын тәэмин итү өчен әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләрне үтәү? | | | | | |
| 14. | Саклана торган табигать ландшафты зонасы, шул исәптән саклана торган табигать ландшафтының бердәм зонасы чикләрендә җирләрдән файдалану режимына һәм шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр үтәләме:<br>а) табигый ландшафтның мәдәни мирас объекты белән, елга үзәннәрен, сулыкларны, урманнарны һәм ачык киңлекләрне кертеп, композицион элемтәне саклап калу һәм торгызу максатларында капиталь төзелеш объектлары төзүне, хуҗалык эшчәнлеген, капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен капиталь ремонтлауны һәм реконструкцияләүне чикләү (территорияне төзекләндерү һәм кече архитектура формаларын урнаштыру эшләреннән тыш);<br>б) саклана торган табигать ландшафтын саклауны һәм торгызуны (регенерацияләүне) тәэмин итү өчен кирәкле әйләнә-тирә мохит сыйфатын саклау;<br>в) мәдәни мирас объектын аның тарихи-шәһәр төзелеше һәм табигать мохитендә визуаль кабул итүне тәэмин итү максатларында саклана торган табигать ландшафтындагы ачык һәм ябык пространстволар чагыштырмасын саклап калу;<br><br>г) мәдәни мирас объектының тарихи һәм ландшафт тирәлегендә, шулай ук саклана торган табигый ландшафтының сакланышын тәэмин итү өчен әйләнә-тирә мохитне саклау | 73-ФЗ номерлы Федераль законның 34 нче статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 нче елның 12 нче сентябрендәге 972 нче номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау зоналары турында нигезләмәнең 11 нче пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | өлкәсендәге таләпләрне үтәү. | | | | | |
| 15. | Истәлекле урын территориясе чикләрендә эшчәнлекне гамәлгә ашыруга таләпләр үтәләме?<br>Искәрмә: истәлекле урын территориясе чикләрендә рөхсәт ителә:<br>- һәйкәлләрне һәм ансамбльләрне саклау буенча эшләр, истәлекле урынның реестрга кертү өчен нигез булып торган һәм һичшиксез сакланырга тиешле үзенчәлекләрен саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшләр;<br>- юкка чыккан шәһәр төзелеше мохитен торгызу максатларында капиталь төзелеш объектларын төзү;<br>- истәлекле урынның реестрга кертү өчен нигез булып торган һәм һичшиксез сакланырга тиешле үзенчәлекләрен саклап калу шарты белән капиталь төзелеш объектларын чикләнгән төзүне, капиталь ремонтлауны һәм реконструкцияләүне гамәлгә ашыру;<br>- мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килми торган һәм мәдәни мирас объектының хәзерге шартларда эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару. | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $5^1$ статьясындагы 1 нче пунктның 2 нче пунктчасы | | | | |
| 16. | Һәйкәл яки ансамбль территориясе чикләрендә эшчәнлек алып баруга таләпләр үтәләме?<br>Искәрмә: һәйкәл яисә ансамбль территориясе чикләрендә: капиталь төзелеш объектларын төзү һәм һәйкәл яисә ансамбль территориясендә булган капиталь төзелеш объектларының күләм-пространство характеристикаларын арттыру; мәдәни мирас объектын яисә | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $5^1$ статьясындагы 1 нче пунктның 3 нче пунктчасы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | аның аерым элементларын саклап калу, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше яисә табигать мохитен саклап калу эшләреннән тыш, җир, төзелеш, мелиорация һәм башка эшләр башкару тыела; мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү таләпләренә каршы килми торган һәм мәдәни мирас объектының хәзерге шартларда эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган хуҗалык эшчәнлеген алып бару рөхсәт ителә. | | | | | |
| 17. | Россия Федерациясенең аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турындагы законнары нигезендә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны мәдәни мирас объектын саклау эшләрен уздыруга кертү турындагы таләп үтәләме? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның 45 нче статьясындагы 6 нчы пунктның беренче абзацы | | | | |
| 18. | Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләре нигезендә объектның ышанычлылыгы һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикаларына кагыла торган мәдәни мирас объектын саклап калу эшләре гамәлгә ашырыламы? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның 45 нче статьясындагы 6 нчы пунктның икенче абзацы | | | | |
| 19. | Мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган юридик затлар яисә индивидуаль | 73-ФЗ номерлы Федераль законның 45 нче статьясындагы 6 нчы пунктның өченче абзацы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | эшкуарлар белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы физик затлар, шулай ук федераль мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган шәхси эшмәкәрләр булганнармы? | | | | | |
| 20. | Мәдәни мирас объектының милекчесе яисә башка законлы хуҗасы, яисә әлеге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләренең заказчысы булып торучы зат тарафыннан күрсәтелгән эшләрне башкаруга рөхсәт биргән мәдәни мирас объектларын саклауның тиешле органы катнашында Казанның мәдәни мирас объектыннан мәдәни мирасны саклап калу эшләрен кабул итү таләбе үтәләме? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның 45 нче статьясындагы 8 нче пункты | | | | |
| 21. | Мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкару таләпләре үтәләме:<br>- күрсәтелгән эшләрне башкаруга бирелгән задание, мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан бирелгән әлеге эшләрне башкаруга рөхсәт нигезендә,<br>- мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга мәдәни мирас объектларын саклауның тиешле органы белән килештерелгән проект документациясе нигезендә,<br>- аларны үткәрүгә техник һәм авторлык күзәтчелеген гамәлгә ашыру шарты белән | 73-ФЗ номерлы Федераль законның 45 нче статьясының 1 нче пункты | | | | |
| 22. | Халыкка хезмәт күрсәтүче учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан файдаланыла торган мәдәни мирас объектларына инвалидларның керә алуын тәэмин итү | 73-ФЗ номерлы Федераль законның 474 статьясы, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | кагыйдәләре, аларның ихтыяҗларын исәпкә алып тулысынча җайлаштырып булмый торган мәдәни мирас объектлары турындагы мәгълүматка инвалидларның керә алуын тәэмин итү оешмасы таләпләре үтәләме? | 2015 елның 20 ноябрендәге 2834 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларыннан инвалидлар өчен файдалана алу шартларын тәэмин итү тәртибе | | | | |
| 23. | Мәдәни мирас объектларының бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектына, ачыкланган мәдәни мирас объектына йә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектка турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясый ала торган җир төзелеше, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык һәм башка эшләр башкарыла башлаганчы тарихи-мәдәни экспертиза үткәрелгәнме? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30-32нче статьялары | | | | |
| 24. | Мәдәни мирас объектында мәдәни мирас объектының яисә аның өлешләренең мәйданын һәм (яисә) биналарының санын үзгәртү эшләре башкарылганмы? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның 40 нчы статьясындагы 3 нче пункты | | | | |
| 25. | Милекче (кулланучы) тарафыннан мәдәни мирас объектын, ачыкланган мәдәни мирас объектын саклау буенча саклау йөкләмәсе, техник торышы акты белән каралган эшләр башкарылганмы? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^2$ статьясы | | | | |
| 26. | Реестрга кертелгән мәдәни мирас объектына милекче яисә башка законлы хуҗаның саклау йөкләмәсе расланганмы? | 73-ФЗ номерлы Федераль законның $47^6$ статьясы | | | | |
| 27. | Тарихи кыйммәткә ия шәһәр | 73-ФЗ номерлы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | формалаштыручы объектның төп күләмен реконструкцияләү һәм (яки) демонтажлау, аның тарихи фасадлар чишелешенең стилистик үзенчәлекләрен үзгәртү, түбә конфигурациясен үзгәртү, фасадларның тарихи бизәлеш материаллары һәм (яки) түбә материаллары алыштырылганмы? | Федераль законның 60 статьясы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Казан шәһәре региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә территория чикләрен, сак предметын һәм шәһәр төзелеше регламентларына таләпләрне раслау турында»13.03.2017 № 218 боерыгы. | | | | |

Инспекторлар төркеме җитәкчесе [1] ___________/______________
(имза) (ФИӘи)

Инспектор ___________/______________
(имза) (ФИӘи)

Инспектор ___________/______________
(имза) (ФИӘи)

[1] Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәргән очракта инспекторлар төркеме составында берничә инспектор тикшерү кәгазен контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүдә катнашучы инспекторларның, шулай ук инспекторлар төркеме җитәкчесенең имзалары белән таныклый («әзерләүгә, эчтәлеккә, иҗтимагый фикер алышуга таләпләрне раслау турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 27 октябрендәге 1844 номерлы карарының 7 пункты). тикшерү кәгазьләре формалары проектлары, тикшерү кәгазьләре формаларын раслау, куллану, актуальләштерү, шулай ук тикшерү кәгазьләрен мәҗбүри куллану очраклары").